СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.03.2019 Алабуга шәһәре № 326

Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендә чыккан 311 санлы « Алабуга муниципаль районының 2019 һәм 2020-2021 елларның планлы чорына муниципаль берәмлекнең бюджеты турында»гы карарга үзгәрешләр кертү турында

«Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турында»гы Нигезләмәгә һәм Россия Федерациясенең Бюджет кодексындагы 83 һәм 86 маддәләренә таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендә чыккан 311 санлы « Алабуга муниципаль районының 2019 һәм 2020-2021 елларның планлы чорына муниципаль берәмлекнең бюджеты турында»гы карарга түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 маддәдә:

*1нче өлештә*

1 пунктта «1 622 589,1» саннарын «1 640 371,7» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «1 622 589,1» саннарын «1 703 405,1» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «0» санын «63 033,4» саннарына алмаштырырга .

*3 нче өлештә*

«2019 елга район Бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары» 1 кушымтасында 1 номерлы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 3 маддәдә:

«2019 елга район Бюджетының фаразланган керемнәр күләме» 1 кушымтасында 1 номерлы таблицада үзгәрешләр кертелгән бүлегендә;

3) 6 маддәдә:

«Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджет керемнәренең югары дәрәҗәдәге төп администраторлар исемлеге» 4 кушымтасының үзгәрешләр кертелгән бүлегендә.

4) 7 маддәдә:

«2019 елга район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 6 кушымтасында 1 номерлы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә;

«Район Бюджетының ассигновать ителгән акчаларын бүлек һәм бүлекчәләргә, максатчан маддәләргә (Алабуга муниципаль районының муниципаль программаларына һәм эшчәнлекнең программалаштырылмаган юнәлешләренә), чыгымнар төрләре төркемнәренә, 2019 елның бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләренә бүлеп бирү» 7 кушымтасында

1 номерлы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

«Район Бюджетының ассигновать ителгән акчаларын максатчан маддәләргә (Алабуга муниципаль районының муниципаль программаларына һәм эшчәнлекнең программалаштырылмаган юнәлешләренә), чыгымнар төрләре төркемнәренә, 2019 елның бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләренә бүлеп бирү» 8 кушымтасында 1 номерлы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

5) түбәндәге эчтәлектәге 14-15 маддәләре белән тулыландырырга:

«14 маддә.

Әлеге Карарның 12 кушымтасына нигезләнеп, 2019 елга җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итәр өчен җирлекләрнең бюджетларыннан муниципаль районнарның бюджетына күчерелгән бюджетара трансфертларның күләмен исәпкә алырга.

15 маддә.

Әлеге Карарның 13 кушымтасына нигезләнеп, 2019 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен авыл җирлекләренә бирелгән бюджетара трансфертларның күләмен расларга».

6) 14-19 маддәләрен 16-21 маддәләре дип санарга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны икътисад үсеше, бюджет, салым, тариф сәясәте, эшмәкәрлеккә һәм туризмга ярдәм итү комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Г.Е. Емельянов